**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **30 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче Митрәй авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Митрәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Митрәй авылы Тау асты, Тукай урамнары буенча вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Митрәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Митрәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Митрәй авылында (зиарат, мәчет, мәдәният йорты территорияләрендә) коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Митрәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Митрәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Митрәй авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәле территориясенең чикләрен алмаштыру.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Идрисов З.Ә.